Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пунктында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"16" ноябрь 2019 ел. № 4/2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Күлле-Киме торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Күлле-Киме авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Күлле-Киме авылында җирлек территориясен чистарту һәм төзекләндерү
- урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү
- урам юлларының асфальт катламын ремонтлау һәм транспорт өчен түләү
- урам су-үткәргечләрен төзекләндерү

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Күлле-Киме авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күлле-Киме авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гәрәев Х.Х.

Совет Кулле-Киминского сельского поселения
Күлле-Киме авыл җирлеге советы
ИНН 1610000589